РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА**

***Красновидовского сельского Поселения Камско-Устьинского муниципального района***

С. Красновидово ул. Советская,4
204-13
факс 204-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

***Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге***

**БАШЛЫГЫ**

С. Красновидово ул. Советская,4
204-13
факс 204-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2021 елның 12 апреле** **№ 3**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында» 2020 елның 16 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турындагы 2020 елның 16 ноябрендәге 4 номерлы карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлегенең Бортас авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданнан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 2021 елда үзара

салымны 500 сум күләмендә кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- авыл эчендәге һәм урамара юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

- кышкы юлларны карап тоту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- җәйге чорда территорияне чабып тору (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- контейнер мәйданчыклары төзү (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- контейнерлар сатып алу, шул исәптән зират өчен (контейнерлар сатып алу).”

2. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Красновидо
авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге башлыгы И.В.Алешин